| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**<br>**ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО**<br>**ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **Татарстан Республикасы**<br>**САРМАН**<br>**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**<br>**ЛӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 30 нчы январь № 2

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2015 елның 22 декабрендәге 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 31.07.2025 N 353-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 4 пунктындагы пунктчасы һәм Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2015елның 22 декабрендәге 11 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаның 4 пунктындагы 4 пунктчасына «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән гражданнан тыш,» сүзләрен өстәргә;

2) 30 кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә: "Адресация объектына адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты" (Кушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru/ адресы буенча Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге Башкарма комитет җитәкчесе Ю.Г.Антонов